**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12 » 10 2018 ел № 280

Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Генераль планы проекты
буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү, Азнакай муниципаль районы халкы хокукларын гавами тыңлаулар уздыру юлы белән Азнакай шәһәре Генераль планы проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен, Азнакай муниципаль берәмлеге халкының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, карар бирәм:

1. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Генераль планы проекты буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә.

2. Халык алдында тыңлаулар уздыруның инициаторы - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башлыгы.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты- 2018 елның 22 октябреннән 2018 елның 23 ноябренә кадәр;
- үткәрелү урыны - Азнакай ш., Ленин ур., 14 йорт;
- 2018 елның 21 ноябренә кадәр - Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин (эш көннәрендә 8.00 дән 17.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына:

- Азнакай муниципаль районының генераль планы проекты буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытта гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;
- Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Генераль планы проекты буенча демонстрацион материаллар күргәзмә-экспозициясен түбәндәге адрес буенча оештырырга: Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 йорт, Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты, 2018 елның 22 октябреннән 2018 елның 23 ноябренә кадәр эш

көннәрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр һәм 13.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

- Азнакай муниципаль районы Генераль планы проектын тикшерү буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эш төркеме составын кушымта нигезендә расларга.

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре Генераль планы проектын тикшерү материаллары һәм әлеге карарны веб-адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

- Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башлык М.З.Шәйдуллин

Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре башлыгы
карарына кушымта

“12 ” 10 2018 № 280

**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Генераль планы проекты буенча фикер алышу буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составы**

| | |
|---|---|
| *Эш төркеме рәисе:* | |
| А.Х. Шәмсетдинов | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| *Эш төркеме сәркатипы:* | |
| Аюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эш төркеме әгъзалары:* | |
| Солтанов М.И. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миндубаева Л.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Вәлиев Н.А. | Азнакай шәһәр Советы депутаты, ПАО «Татнефть» НГДУ «Азнакайнефть» гомуми мәсьәләләр, кадрлар һәм социаль үсеш буенча җитәкче урынбасары |
| Мугтасимов Р.Р. | Азнакай шәһәре Советы депутаты, «Азнакай муниципаль районының Торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү департаменты» муниципаль унитар предприятиесе директоры (килешү буенча) |
| Алчина Э.А. | Азнакай шәһәре Советы депутаты, «Универсал-Азнакай» ИК ҖЧҖ генераль директоры, Совет әгъзасы (килешү буенча) |